Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

20.06.2025_________ Менделеевск ш. №408

Күпфатирлы йортта бинаны
үзгәртеп коруны һәм (яисә) яңадан
планлаштыруны килештерү һәм
кабул итү комиссиясе тарафыннан
күпфатирлы йортта биналарны яңадан
үзгәртеп кору һәм (яисә) яңадан
планлаштыру турында актны
рәсмиләштерү буенча муниципаль
хезмәт күрсәтүнең административ
регламентына үзгәрешләр кертү хакында

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 июлендәге 550 номерлы карары белән расланган күпфатирлы йортта бинаны үзгәртеп коруны һәм (яисә) яңадан планлаштыруны килештерү һәм күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп кору һәм (яисә) яңадан планлаштыру турында актны кабул итү комиссиясе тарафыннан рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1. Административ регламентның 1.5 пунктындагы 6 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"күпфатирлы йортта урынны үзгәртеп планлаштыру мондый бинаның чикләрен һәм (яисә) мәйданын үзгәртүдән һәм (яисә) яңа биналар булдырудан, шул исәптән әлеге Кодексның 40 статьясында каралган очракларда, һәм (яисә) аның эчке планлаштыруын үзгәртүдән (шул исәптән бинаның чикләрен һәм (яисә) мәйданын үзгәртмичә) гыйбарәт. Бинаны яңадан планлаштыру нәтиҗәсендә чиктәш биналарның чикләре һәм (яисә) мәйданы да үзгәртелергә мөмкин. Яңадан планлаштыру бинаның (урыннарның) чикләре һәм (яисә) мәйданы турында бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестры белешмәләренә үзгәрешләр кертү яисә төзелгән биналарны дәүләт кадастр исәбенә алу һәм төзелгән биналарга хокукны дәүләт теркәвенә алу кирәклегенә китерә.»

2. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында

www.mendeleevsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары А.Ф. Искаковка йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Искәндәров